| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

22.10.2025 г. Казань № 253-4/э-2025

«Энерго – Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2021 №526-23/э-2021 карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2026 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 22.10.2025 ел, №20-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы индивидуаль тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына 2026 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022-2026 елларга «Энерго - Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында челтәр оешмалары арасында

үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 15.12.2021 ел, №526-23/э-2021 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.11.2022 ел, №272-9/э-2022, 13.12.2023 ел, №542-18/э-2023, 19.11.2024 ел, №335-8/э-2024 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
15.12.2021 ел, №526-23/э-2021
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
22.10.2025 № 253-4/э-2025
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2022 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Энерго-Про» акционерлык җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2022 | 279 682,50 | 297,85 | 1,00637 | 279 682,50 | 297,85 | 1,00637 |
| | | 2023 | 575 797,34 | 331,83 | 1,4523 | 575 797,34 | 331,83 | 1,4523 |
| | | 2024 | 380 563,65 | 322,03 | 1,0919 | 380 563,65 | 322,03 | 1,0919 |
| | | 2025 | 413 910,13 | 328,27 | 1,18553 | 413 910,13 | 328,27 | 1,18553 |
| | | 2026 | 258 713,120 | 393,21 | 1,08173 | 258 713,120 | 393,21 | 1,08173 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 ел, №526-23/э-2021
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
22.10.2025 № 253-4/э-2025
карары редакциясендә)

## «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2022-2026 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының исеме | Ел | Челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1 | «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2022 | 26 924,15 |
| | | 2023 | 58 268,09 |
| | | 2024 | 67 770,78 |
| | | 2025 | 84 785,35 |
| | | 2026 | 68 095,08 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге